КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 30 ноябрь г.Казань № б-2680

Россия Федерациясе Җир кодексының 70[1] статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлауга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләрен резервлау турында» 2004 елның 22 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы дәүләт җир резервларына кертү һәм алардан алга таба файдалану мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт җир резервлары фонды һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 21 гыйнвар, 15 нче карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Җирләрнең дәүләт резерв фондының дәүләт ихтыяҗлары өчен торак төзелеше максатында Казан шәһәре, Совет районы, 3 нче Кленовая урамында урнашкан «торак пунктлары җирләре» җирләр категориясендәге, «урта катлы торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төрендәге 1,9172 гектар гомуми мәйданлы, 16:50:250232:239 кадастр номерлы җир кишәрлеген кушымта нигезендә өч елга Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеге милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләренең, арендаторларының хокуклары торак, җитештерү, мәдәният-көнкүреш һәм башка биналар, корылмалар төзү өлешендә дәүләт ихтыяҗлары өчен аны резервлауга бәйле рәвештә чикләнә;

бу боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертү Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының «Җир кишәрлеген Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына тапшыру турында» 2023 ел, 22 сентябрь, 2808 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бу боерыкның 1 нче пункты нигезендә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү өчен документларны Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

5. Бу боерык резервлана торган җир кишәрлеге урнашу урыны турындагы мәгълүматны рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш һәм басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 30 ноябрь, б-2680 нче
боерыгына кушымта

## Территория чикләренең характерлы нокталары координатлары исемлеге
## (16:50:250232:239 кадастр номерлы җир кишәрлеге)

| Җир кишәрлеге чигенең характерлы нокталары турында белешмә | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Координаторлар системасы: Халыкара координатлар системасы-16 | | | | |
| Нокта номеры | Координатлар, м | | Җирлектә беркетү тасвирламасы | Җир кишәрлеге чикләренең характерлы нокталарын билгеләүнең уртача квадрат төгәлсезлеге, м |
| | X | Y | | |
| 1 | 484879.95 | 1313004.54 | - | 0.1 |
| 2 | 484913.26 | 1313005.86 | - | 0.1 |
| 3 | 484926.76 | 1313111.48 | - | 0.1 |
| 4 | 484914.33 | 1313111.23 | - | 0.1 |
| 5 | 484872.95 | 1313105.54 | - | 0.1 |
| 6 | 484806.85 | 1313091.56 | - | 0.1 |
| 7 | 484743.96 | 1313075.32 | - | 0.1 |
| 8 | 484675.63 | 1313079.6 | - | 0.1 |
| 9 | 484657.38 | 1313036.44 | - | 0.1 |
| 10 | 484672.89 | 1313030.73 | - | 0.1 |
| 11 | 484696.62 | 1313024.74 | - | 0.1 |
| 12 | 484736.01 | 1313017.76 | - | 0.1 |
| 13 | 484771.57 | 1313007.12 | - | 0.1 |
| 14 | 484780.75 | 1313007.08 | - | 0.1 |
| 15 | 484790.61 | 1313007.05 | - | 0.1 |
| 16 | 484810.99 | 1313010.1 | - | 0.1 |
| 17 | 484834.63 | 1313013.65 | - | 0.1 |
| 18 | 484835.48 | 1313013.77 | - | 0.1 |
| 19 | 484835.18 | 1313017.11 | - | 0.1 |
| 20 | 484875.49 | 1313020.67 | - | 0.1 |
| 21 | 484876.35 | 1313005.17 | - | 0.1 |
| 1 | 484879.95 | 1313004.54 | - | 0.1 |

______________________________